# Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Х.Сабурскаяның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында ясаган чыгышы тезислары

20.02.2020 Татарстан Республикасы Дәүләт Советы

**Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич! Минтимер Шәрипович!**
**Фәрит Хәйруллович!**
**Халык депутатлары, чакырылган катнашучылар!**

1. Вәкаләтле вәкилнең «Татарстан Республикасында 2019 елда кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында»гы әлеге доклады 2000 елның 3 мартында дөнья күргән 95 нче «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында»гы Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсенә ярашлы рәвештә әзерләнде һәм гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә, тикшерү йомгакларына, Вәкаләтле вәкил баш модератор булган «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә, дәүләт хакимияте органнарының статистика мәгълүматларына, ГЛОНАСС 112 системасы аша алынган мәгълүматларны карау нәтиҗәләренә нигезләнә.

2. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына турыдан туры килгән мөрәҗәгатьләр саны, 2019 елда (ике мең унтугызынчы елда) бер меңгә күбрәк булды һәм 4713 не (дүрт мең җиде йөз унөчне) тәшкил итте. Мөрәҗәгатьләр структурасы үзгәрмәде диярлек. Аларның күбесе хезмәт, торак мөнәсәбәтләренә, сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә, белем алуга, социаль яклау чараларына хокукны тәэмин итүгә кагылышлы.

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләр саны арту моңа дәлил булып тора, 2019 елда әлеге система аша 77 162 мөрәҗәгать керде, бу 2018 елга караганда 26 процентка күбрәк (узган ел – 61 378).

2018 ел белән чагыштырганда гражданнарның мөрәҗәгатьләрен уңай хәл итү очраклары да артты (60 052 – 2019 елда, 47 768 – 2018 елда), бу 2019 елда бастырылган барлык мөрәҗәгатьнең 78 проценты.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкил 2019 елда 3401 мөрәҗәгатьнең (өч мең дүрт йөз бер) үтәлешен контрольгә алды. Күрсәтелгән чорда ЕГИС ГЛОНАСС 112 системасы аша кергән 541 (биш йөз кырык бер) мөрәҗәгатьне тикшерү үткәрелде.

Аппаратка мөрәҗәгать иткән гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча, 100 урынга барып тикшерү үткәрелде. Гомуми юрисдикция судларында гражданнар мәнфәгатьләрен яклап яки өченче зат сыйфатында Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләре яки аның вәкилләре 60 тапкыр катнашты.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил хезмәт, миграция мөнәсәбәтләре, торак, социаль өлкә, белем бирү һәм сәламәтлек саклау өлкәләрендә гражданның бозылган ирекләрен һәм хокукларын торгызу буенча кирәкле чаралар күрергә кирәклеге әйтелгән тәкъдимнәр белән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, шул исәптән аларның җаваплы вазифадагы затларына, шул исәптән идарәче компанияләр, торак-төзелеш кооперативлары, торак милекчеләре ширкәте, гомуми белем бирү учреждениеләре, спорт-сәламәтләндерү комплексы, республиканың муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары һәм башка субъектлар адресына тәкъдимнәре, шелтәләре һәм заключениеләре җибәрелде.

3. Гражданнарның хезмәткә хокукларын тәэмин итү буенча шактый дәрәҗәдә эш хакы, аның дәрәҗәсе һәм үзвакытында түләве белән бәйле вәзгыять, эштә чагылыш таба.

Республикада эш хакы буенча бурычны ачыклау һәм тиешле чаралар күрү буенча системалы эш алып барыла. Шул ук вакытта, тулаем алганда, хәл катлаулы дип әйтергә кирәк. Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматларына караганда, агымдагы ел башына эш хакы буенча бурыч 305,8 миллион (өч йөз биш бөтен уннан сигез миллион) сум тәшкил итте.

Шактый бурыч бөлгенлеккә чыккан предприятиеләр аркасында җыелды һәм бу проблемага зур әһәмият бирелә башлады. Республикада арбитраж идарәчеләренең суд канәгатьләндергән, икенче чират кредиторларның агымдагы таләпләрен үтәүнең айлык чиратын үзгәртү турында Татарстан Республикасы Арбитраж судына гаризалар җибәрү практикасы барлыкка килә башлады һәм хезмәткәрләргә эш хакын беренче чиратта түләү тәртибе билгеләнде. Шуның белән бергә, тиешле чаралар һәр очракта һәм икътисадый

яктан актив бурычлы оешмаларга карата да кабул ителергә тиеш.

Аерым алганда, бу эштә бигрәк тә Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясенә, элеккеге хезмәткәрләре белән исәп-хисап ясамаган һәм салым органына хәбәр итмичә факттагы адресын үзгәрткән эш бирүчеләргә карата принципиаль булу таләп ителәдип саныйм.

Әйтеп үтелгән контроль-күзәтчелек органына мөрәҗәгать иткәннән соң безгә Яшел Үзән шәһәрендә яшәүче үзенең элеккеге эш бирүчесе – «Фактор» оешмасына шикаять белән килде. Хезмәт инспекторлары кебек үк без дә мөрәҗәгать итүче күрсәткән оешма адреслары буенча урынга бардык. Оешманың әлеге адресларда эш алып баруын ачыклый алмадык, ләкин мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән ике айдан артык эш хакы алмау турындагы мәгълүматны игътибарсыз калдыра алмадык. Тикшерү органнарына мөрәҗәгать иттек, алардан, эш бирүче табылды, шикаять язучыга тиешле акчаны түләде, дигән җавап килде. Бу беренче очрак кына түгел. Түләргә сәләтле бурычлы оешма эшчәнлеге белән хокук саклау органнары кызыксына башлау белән, шунда ук үз хезмәткәрләренә бурыч түләү мөмкинлеген табулары турында без бер генә тапкыр билгеләп үтмәдек. Конкрет саннарга таянып шуны билгеләп үтәм, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасындагы тикшерү идарәсе мәгълүматлары буенча 2019 елда алдан тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә республиканың дүрт предприятиесендә эш хакы буенча бурыч тулысынча түләнеп бетте.

Бу – Чаллы шәһәренең «Регион-Бетон», Баулы районының «Поповка», Казан шәһәре Совет районының «Ермак ЧОО», Казан шәһәре Совет районының «Вектор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләре.

Гражданнарның хезмәткә хокукларын тәэмин итү халык мәшгульлегенә булышлык итүне дә үз эченә ала. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда ел дәвамында эшсезлек дәрәҗәсе Россия Федерациясендәге һәм Идел буе федераль округындагы уртача күрсәткечтән һәрвакыт түбән булды.

Кызганычка каршы, гражданнарның конкрет тормыш хәлләре гомуми саннар чагылышыннан аерылып тора. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасының эш урыннарына квота һәм резерв калдыру турындагы законына ярашлы рәвештә эшкә

урнаша алмаган инвалидларны эшкә урнаштыруга юнәлтелгән өстәмә чаралар күрергә кирәк дип саныйбыз. Әйтик, Лаеш районында, шул исәптән әлеге сәбәп буенча да, мәшгульлек органнары инвалид булган кешене берничә ел буе эшкә урнаштыра алмаганнар. Статистика мәгълүматлары шуны күрсәтә, инвалидның эшсезлек чоры дәвамлылыгы республика уртача күрсәткеченнән күбрәк.

Гражданнарның хезмәткә хокукларының аерылгысыз өлеше булып куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү тора. Ел ахырында республикада «Татарстан Республикасында хезмәт законнарына һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актларга күзәтчелек буенча ведомство контроле турында»гы закон кабул ителде. Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматларын анализлау шуны күрсәтә, узган ел хезмәткәрләрнең сәламәтлегенә авыр зыян китерә торган җитештерүдәге бәхетсезлек очраклары, кайсы оештыру-хокукый милек формасына бәйле булуына карамастан оешмаларда булды. Шушы уңайдан җитештерүдәге имгәнүләр профилактикасы максатларында, докладта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына һәм җирле үзидарә органнарына, җитештерүдә эш вакытында хезмәткәрләре белән бәхетсезлек очраклары булган оешмаларны алда әйтелгән законга ярашлы рәвештә үткәрелә торган тикшерүләр планына кертү турындагы мәсьәләне карау тәкъдим ителә.

4. Вәкаләтле вәкил Аппаратына торакка хокуклары бозылу турындагы мөрәҗәгатьләр - берничә ел дәвамында иң күп килгәне. 2019 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына торак законнары белән көйләнә торган мөнәсәбәтләр өлкәсенә кагылган 1081 мөрәҗәгать керде.

Докладта инвалидларның һәм аз якланган башка төркемнәрнең, йортлары сәнагать әһәмиятендәге объектлар зонасы чикләренә эләккән, социаль найм килешүе буенча торак алуга хокуклары булган гражданнарның хокукларын яклау белән бәйле хәлләр буенча безнең катнашу турындагы мисаллар китерелә.

Вәкаләтле вәкилгә торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсе оешмалары эшенә шикаятьләр килү дәвам итә.

Әлеге тема елдан ел республикада яшәүчеләр өчен актуаль булып кала. Татарстанлыларны агымдагы ремонт үткәрүдә, гомум йорт милкен һәм йорт яны территорияләрен тиешле тәртиптә тотуда

идарәче оешмаларның эшләмәве, идарәче оешмаларның үз эшчәнлеге турында мәгълүмат бирмәве, коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең тиешенчә булмавы белән бәйле мәсьәләләр борчый.

Без моны 2018 елның мартында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча кертелгән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша ала торган социаль әһәмиятле хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү Сервисы аша җибәрелгән бәяләр һәм Вәкаләтле вәкилгә гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне анализлау нәтиҗәсендә дә күзәтәбез.

Күрсәтелгән социаль әһәмиятле хезмәтләр арасында торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре дә бар.

2019 елда республикада яшәүчеләр 165 584 бәя калдырды. Сервистан кулланучыларның күбесе йортны тотудан (54 034 бәя), йорт ремонтлаудан (44 290), коммуналь хезмәтләрдән (35 214) һәм йорт белән идарә итүдән (34 323) канәгать түгел.

Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү гражданнарның уңайлы яшәү шартларын тәэмин итүгә юнәлтелгән. Вәкаләтле вәкил республикада яшәүчеләр белдергән шелтәләр идарәче оешмалар эшендә исәпкә алыныр дип ышана.

5. Республикада сәламәтлек саклау өлкәсендә сәламәтлек саклау объектлары инфраструктурасын үстерүгә, сәламәтлек саклау учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итүгә, республикада яшәүчеләр өчен профилактик чаралар оештыруга ныклы игътибар бирелә. Шуның белән бергә, сәламәтлек саклау өлкәсендәге теләсә кайсы уңышлар янында хокук бозулар тиз күренә, чөнки алар һәр кешенең мөлкәти булмаган шәхси хокукларына, аның сәламәтлегенә кагыла.

Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төре буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне анализлау барышында шул игътибарны җәлеп итә, 2019 елда гражданнардан килгән иң күп мөрәҗәгатьләр табибка язылуга кагылышлы иде. Вәкаләтле вәкил докладында пациентларның табиб-белгечләргә үзвакытында язылa алмавы турында конкрет мисаллар китерелә.

Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтүгә дәүләт гарантияләре программасы кысаларында амбулатор-

сырхауханә ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларындагы белгечләргә үзвакытында язылуны оештыруга юнәлтелгән өстәмә чаралар кабул итү үтенече белән мөрәҗәгать итәм.

Сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукны саклауга аерылгысыз элемент булып – сәламәтлеген югалткан очракта гражданнарның социаль яклануы тора. 2019 елның май аенда кешене инвалид итеп тану кагыйдәләренә үзгәрешләр үз көченә керде, аңа ярашлы рәвештә граждан медико-социаль экспертизага гражданның (аның законлы яки вәкаләтле вәкиле) язмача ризалыгы белән җибәрелә.

Әлеге үзгәрешләр уңаеннан кайбер очраклар җайга салуны да таләп итә.

Докладта авырып урында ятучы кешенең туганнары авыр хәлдәге якыннарын инвалид итеп тану өчен аның мәнфәгатьләрен яклауга ышаныч кәгазе булмау аркасында инвалидлык ала алмаганнар, һәм акылга зәгыйфь дип тә танылмаган.

Алексеевский районыннан шундый мөрәҗәгать килгәч без аны тикшерергә булдык. Шуннан соң кешегә килеп, аңа өйдә медицина тикшеренүләре үткәреп медико-социаль экспертизага юллама бирделәр. Үз чиратында мондый мисал кагыйдәдән искәрмә булуын теләмәс идек. Шушы уңайдан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына мондый очракларда сәламәтлек саклау учреждениеләренә нишләр эшләргә кирәклеге турында гомуми аңлатмалар җибәрүне сорап мөрәҗәгать итәбез.

6. Хисап елында балаларга һәм үсмерләргә белем бирү, тәрбияләүгә кагылышлы мөрәҗәгатьләр дә артты.

Республикада яшәүчеләрне, беренче баскычы мәктәпкәчә белем бирү булган уңайлы һәм сыйфатлы белем белән тәэмин итү Татарстан дәүләт сәясәтенең өстенлек юнәлешләренең берсе булып тора. Яңа балалар бакчалары төзүгә һәм ачуга карамастан, урыннар җитмәү аркасында кабул ителмәгән сабыйлар чираты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, кызганычка каршы, артты.

Чиратны «бушату» вариантларының берсе – шәхси балалар бакчалары, алар үзләрен белем бирмичә генә балаларны карау һәм тәрбияләү буенча хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләр сыйфатында гына күрсәтә. Казанда үткәрелгән тикшерүләребез һәм башка дәүләт

органнары мәгълүматлары нигезендә без әлеге учреждениеләрдә булу балалар өчен куркынычсыз булмавын күрдек.

Андый учреждениеләргә эшләргә бирмәү – иң җиңел карар. Ләкин, балаларын бу учреждениеләргә бирергә мәҗбүр булган ата-аналар һәм балаларның үзләренең мәнфәгатьләрен дә искә алырга кирәк, дип саныйм. Хәзерге шартларда, җирле үзидарә органнары ата-аналар өчен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә альтернатива булган учреждениеләрнең эшен сыйфатлы итеп оештыруга кызыксыну күрсәтергә тиеш. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына муниципалитетлар белән бергә шундый шәхси бакчаларга методик ярдәм күрсәтүнең төрле вариантларын карау максатка ярашлы булыр иде дип саныйм.

7. Икътисадый үсеш өлкәсендә теләсә кайсы уңыш, әгәр бер үк вакытта җәмгыятьнең социаль аерымлыгын киметүгә юнәлтелгән чаралар кабул ителмәсә, кешеләр өчен сизелмәячәк.

Социаль яклау өлкәсендә гражданнар хокукларын саклау – докладның тагын бер бүлеге, анда пенсия белән тәэмин итү, мохтаҗ гражданнарга социаль түләүләр, социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты, инвалидларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү, аерым төр гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү, республиканың санатор-курорт учреждениеләрендә инвалидлар һәм аз хәрәкәтләнә торган кешеләр өчен уңайлы тирәлек булдыру белән бәйле аерым проблемалы мәсьәләләр кертелде.

Ачыкланган хокук бозулар һәм кеше хокукларын тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрелмәү уңаеннан докладта Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегенә, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды төбәк бүлегенә, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына тиешле тәкъдимнәр бирелде.

8. Күрсәтелгән мәсьәләләрдән тыш докладта миграция мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын саклау, пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затлар хокукларын саклау турында бүлекләр кертелде, шулай ук хокук мөнәсәбәтләренең башка өлкәләрендәге аерым проблемалы хәлләрне анализлау нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

9. Хөрмәтле депутатлар һәм чакырылган кешеләр! 2019 елның декабрендә Кремльдә кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр

белән очрашуда Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин безнең илдәге омбудсман институты концепциясен тулы чагылдырды, кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләргә мөрәҗәгать итеп, ул болай диде: «Сезнең кешеләр белән турыдан туры эшләү, аннан бу проблемаларны хакимиятнең тиешле органнары аша хәл итүгә ирешү мөмкинлегегез бар. Түрәләрнең куллары җитмәгән яки проблеманы тоймаган урыннарда Сез булырга тиеш».

Үз чиратында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эше аерым гына алып барылмый. Ел дәвамында без хокук саклау эшчәнлеген дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, республика уку йортлары, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары белән бергәләп тормышка ашырдык.

Хокук саклау эшчәнлегендә бергәләп эшләгән өчен депутат корпусына аерым рәхмәтемне әйтәсем килә. Халыкта кызыксыну уяткан кайбер партнерлык практикасы даимигә әверелде. Менә берничә ел инде Вәкаләтле вәкилнең хокук мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе белән үткәргән «кайнар элемтәләр»е, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары белән бергәләп гражданнарны кабул итүләр республикада яшәүчеләрдә зур кызыксыну уята.

Әлеге докладның эчтәлегендә без үткән елда җәмәгатьчелектә кызыксыну уяткан вакыйгаларны да читләтеп үтмәдек, ләкин, элеккеге еллардагы кебек үк, безнеңчә җитәрлек билгеләп үтелмәгән, хокук эшчәнлегендә конкрет идарә карарлары таләп иткән проблемаларга да игътибарны юнәлттек. Әлеге докладта ясалган нәтиҗәләр безнең республикада кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны өстәмә дәүләт гарантияләре белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирер дип ышанам.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!